Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

---

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2020 ел, 24 ноябрь

№ 13

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында» карар проекты

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорынабюджеты турында» карар проектын кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына бюджеты турында» карар проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:

1. Газизов Данияр Әнвәр улы-төркем җитәкчесе
2. Вәлиәхмәтов Радик Габдрәүф улы-төркем әгъзасы
3. Сафина Айназ Фаиз кызы-төркем әгъзасы

4. Карар проектына гражданнарның тәкъдимнәре язма рәвештә, авторның исем фамилиясе, туган елы, адресы күрсәтелеп , эшче төркемгә түбәндәге адреска җибәрелә: ТР, Сарман муниципаль районы Әлмәт авылы, Ленин урамы, 56а йорт, т. 4-23-76

5. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 нче елга һәм 2022, 2023 нче елларның планлы чорына бюджеты турында " карар проекты буенча ачык тыңлауларны 2020 елның 8 декабренә 14 сәгатькә билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы депутатлары төзәтмәләрен һәм карар проектына

гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы каравына 2020 елның 11 декабренә кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге Совет Рәисе Д. А. Газизов

Республика Татарстан
Совет Альметьевского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районы Әлмәт авыл
җирлеге советы

---

20__ ел №

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль
районы Әлмәт авыл җирлегенең 2021 елга
һәм 2022, 2023 еллар планлы чорына бюджеты турында**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар итте:

1 статья

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл жирлеге бюджетының 2021 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджет керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 2958,0 мең сум;

2) Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл жирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2958,0 мең сум;

3) Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл жирлеге бюджет дефициты 0,0 мең сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетының 2021 елга һәм 2022 елга төп характеристикаларын расларга:

1) Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2022 елга бюджет керемнәренең гомуми күләме 2999,2 мең сум һәм 2023 елга 3006,7 мең сум булыр дип фаразлана;

2) 2021 елга Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2999,2 мең сум, шул исәптән 75,0 мең сум шартлы рәвештә расланган чыгымнар һәм 2023 елга 3006,7 мең сум күләмендә, шул исәптән 150,0 мең сум шартлы рәвештә расланган чыгымнар;

3) Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджеты дефициты 2021 елга 0,0 мең сум һәм 2022 елга 0,0 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2021 нче елның 1 гыйнварына Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2022 нче елның 1 нче гыйнварына Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2023 нче елның 1 нче гыйнварына Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең муниципаль эчке бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә, шул исәптән Сарман муниципаль районы Әлмәт җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3 статья

Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетында 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең бюджетының фаразланган керемнәре күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 статья

1. Сарман муниципаль районының Әлмәт авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге муниципаль программалары, бүлекчәләре, максатчан статьялары (эшчәнлек программасы һәм программаның программалаштырылмаган

юнәлешләре), 2021 елга һәм 2022, 2023 ел план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл жирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә 2021 елга һәм 2022 , 2023 ел план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл жирлеге муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программа булмаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекчәләре буенча бүлүне расларга.

4. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл жирлеге бюджетының 2021 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0,0 мең сум күләмендә, 2022 елга 0,0 мең сум күләмендә, 2023 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

6 статья

1. Җирлек халкын ял итүне оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыруга Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетыннан Сарман муниципаль районы бюджетына 2021 елда 1171,1 мең сум, 2022 елда 1515,2 мең сум, 2023 елда 1262,3 мең сум күләмендә күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмендә расларга.

2. 2021 елда әлеге статьяда каралган Әлмәт җирлеге бюджетыннан субсидияләр ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә

7 статья

Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетында Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган средстволарны исәпкә алырга:

1) авыл җирлекләре бюджетларына 2021елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 68,8 мең сум, 2022 елга 102,5 мең сум, 2023 елга 101,8 мең сум күләмендә дотацияләр.

2) 2021 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына 100,00 мең сум күләмендә субвенция, 2022 елга 101,0 мең сум күләмендә, 2023 елга 105,1мең сум күләмендә.».

8 статья

Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге җирле үзидарә органнары 2021 елда муниципаль хезмәткәрләр, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

9 статья

1. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетының 2021 елның 1 гыйнварына калган акчалары, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарлар белән тәэмин итү, эшләр башкару, әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2020 елда түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, 2021 елда Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

2. Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты 2021-2023 елларда әлеге статьяның 1 өлешендәге 1 абзацында каралган максатларга чыгымнарны тормышка ашырганнан соң, законда билгеләнгән тәртиптә гидротехник корылмаларны тотуга 50 мең сум күләмендә өстәмә керемнәр җибәрергә хокуклы.

10 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

11 Статья

Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан стендларда халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында», (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

12 Статья

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

13 Статья

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы рәисе Д.Ә.Газизов